ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 9 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның ундүртенче абзацында «, шулай ук хәрби гамәлләр үткәрелгәндә яисә шушы гамәлләр аркасында барлыкка килә торган куркынычлар турында,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 9 статьяның беренче өлешендәге уналтынчы абзацында «гражданнарга» сүзен «Россия Федерациясе гражданнарына, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 13 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 26 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«гражданнар оборонасы белән идарә итүнең техник системаларын, халыкка

хәбәр итү системасын, саклагыч корылмаларны һәм гражданнар оборонасының башка объектларын булдыра, аларга реконструкция үткәрә һәм аларны файдалану өчен даими әзерлек хәлендә тота;»;

2) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«халыкка үз вакытында хәбәр итүне тәэмин итә һәм гамәлгә ашыра;».

**3 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктыннан һәм 2 статьясыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты һәм 2 статьясы 2023 елның 4 маеннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 23 декабрь
№ 94-ТРЗ